**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

29 нчы сентябрь 2017 ел №122

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10 статьясы, Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 27 сентябрендәге 8 номерлы «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында»гы карары, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 сентябрендәге 121 номерлы «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында»гы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. 2017 елның 19 ноябренә Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2018 елда Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

1. Авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;

2. Ирекле янгын сүндерү машинасын карап тоту, шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу;

3. Балалар мәйданчыгын урнаштыру, шул исәптән кече архитектура формаларын сатып алу;

4. Смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».».

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**